ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 20 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 4 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 1 – 2; 2011, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 5; 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2018, № 78 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктта «кече һәм урта» сүзләрен «кече яисә урта» сүзләренә алмаштырырга;

2) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) кече яисә урта эшкуарлык субъекты ярдәм күрсәтү тәртибен һәм шартларын бозган дип танылган вакыттан бер елдан кимрәк вакыт үткән булса, кече яисә урта эшкуарлык субъектының ярдәм күрсәткән орган яисә оешма тарафыннан мондый хокук бозуны бетерүгә билгеләнгән срокны үтәве шартында аның мондый хокук бозуны элегрәк бетерү очрагыннан тыш, ә ярдәм күрсәтү тәртибен һәм шартларын бозу ярдәм күрсәтү чараларыннан максатчан файдаланмауга яисә дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшыруга бәйле булганда, кече яисә урта эшкуарлык субъекты мондый хокук бозуны кылган дип танылган вакыттан өч елдан кимрәк вакыт үткән булса. Әлеге пунктта каралган нигезләмәләр ярдәм күрсәткән орган яисә оешма тарафыннан кече яисә урта эшкуарлык субъектының ярдәм күрсәтү тәртибен һәм шартларын бозулары ачыкланган ярдәм күрсәтү төрләренә кагыла.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пункты 2022 елның 26 декабреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 02 ноябрь
№ 81-ТРЗ